СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

31.03.2025 № 56/5
На №_________ от_____________

## КАРАР

### Тукай муниципаль районында 2024 ел өчен авыл халкының эшлекле активлыгын арттыру буенча эш нәтиҗәләре һәм 2025 елга бурычлар турында

«Татарстан Республикасы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2016 елның 12 январендәге 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы нигезендә муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Мәгълүматны игътибарга алырга.

2. Район Башкарма комитетына шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнар белән җитештерелгән һәм эшкәртелгән авыл хуҗалыгы продукциясен сату максатында эшне дәвам итәргә.

3. Авыл җирлекләре Башлыкларына шәхси ярдәмче хуҗалыкларны саклап калу һәм терлекләрнең баш санын киметмәү буенча эшне контрольдә тотарга, шәхси ярдәмче хуҗалыкларга кече фермалар төзүгә ярдәм итәргә тәкъдим итәргә.

4. Тукай районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенә тәкъдим итәргә:

- халыктан әзерләүчеләр тарафыннан сатып алына торган продукциянең барлык төрләре өчен сатып алу бәяләре дәрәҗәсенә ай саен мониторинг ясарга;
- Тукай районының крестьян (фермер) хуҗалыклары ассоциациясе, авыл хуҗалыгы кооперативлары һәм шәхси хуҗалыклары белән берлектә, авылда кече хуҗалыкларга ярдәм итү буенча дәүләт программаларында катнашу өчен, булдыклы фермерларны, шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарны сайлап алу буенча эшне дәвам итәргә.

5. «Якты юл» («Светлый путь») газетасы редакциясенә халык хуҗалыкларының, фермерларның, авыл хуҗалыгы кооперативларының, авыл җирлегендә эшмәкәрлекнең башка формаларының уңай эш мисалларын даими яктыртырга тәкъдим итәргә.

6. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны социаль сәясәт, инфраструктура үсеше һәм аграр мәсьәләләр буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет Рәисе вазыйфаларын башкаручы

Р.И. Закиров